**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

2023 елның 30 июне | 72-РС номер

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлегенең 2003 елның 14 июнендәге 32-53/7136 номерлы Генераль планы проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсен, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2022 елның 13 апрелендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне карап,Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар чыгарды**:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлегенең Генераль планы проектын (1 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.
4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**